ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ЛЕНИНОГОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»

«ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.03.2026 г.Лениногорск № 212

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2025 елның 20 ноябрендәге 997 номерлы карары белән расланган «2026-2030 елларга Лениногорск муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү» программасына («Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 28.01.2026 № 42 карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) үзгәрешләр кертү турында

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Советының «2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы бюджеты турында» 2025 елның 15 декабрендәге 39 номерлы карарын үтәү йөзеннән Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2025 елның 20 ноябрендәге 997 номерлы карары белән расланган «2026-2030 елларга Лениногорск муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү» программасына («Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 28.01.2026 № 42 карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программа паспортында:

«Программаны еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп финанслау күләме» бүлегенә түбәндәге редакциядә «2026 елга республика бюджеты исәбеннән» юл өстәргә:

Лениногорск муниципаль районы спорт мәктәпләре спортчыларын йөртү буенча аутсорсинг белән бәйле чараларны гамәлгә ашыруга 1397,36 мең сум;

Татарстан Республикасының спорт резервын әзерләүче Лениногорск муниципаль районы муниципаль физкультура спорт оешмаларын тәэмин итү өчен спорт җиһазлары, экипировка һәм инвентарь сатып алуга 776,24 мең сум;

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Хоккей буенча «Нефтяник» спорт мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесенең спорт командаларын спорт әзерлеге һәм катнашуы буенча Татарстан Республикасы чемпионатында хоккей буенча Татарстан Республикасы чемпионатында һәм хоккей буенча Россия Федерациясе чемпионатында (А төркемчәсе) 894,10 мең сум.».

Программаның 3 нче кушымтасын кушымтада бирелгән яңа редакциядә расларга.

2.Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Г.Х. Вагыйзовага йөкләргә.

Җитәкче И.Г.Шәмәрданов

М.М.Хәсәнов
5-49-40

3 нче кушымта

«2026-2030 елларга Лениногорск муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү» муниципаль программасына

## «2026-2030 елларга Лениногорск муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү» муниципаль программасының максатлары, бурычлары һәм программа чаралары буенча финанслау

| № т/б | Максатның исеме | Бурычның исеме | Чараның атамасы | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү сроклары, еллар | Финанслау чыганагы | Финанслау, мең сумнарда |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | 2026 |
| 1. | Лениногорск муниципаль районында физик культура һәм спорт өлкәсендә дәүләт сәясәте программасын гамәлгә ашыру | Массакүләм физик культураны һәм спортны үстерү, халыкның сәламәтлеген ныгыту, Лениногорск районының спорт имиджын ныгыту | Лениногорск муниципаль районының спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен тренер-укытучыларга, шулай ук спортчы-инструкторларга һәм спортчыларга ярышларда алган нәтиҗәләре өчен бүләкләү | «Яшьләр эшләре спорт һәм туризм идарәсе» МКУ | 2026 | Республика бюджеты | 1200,00 |
| 2. | | | Хезмәткәрләргә-Лениногорск муниципаль районы физкультура спорт | | 2026 | Республика бюджеты | 20,00 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | оешмаларының спорт әзерлегенең өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы яшь белгечләренә акчалата түләү | | | | |
| 3. | | | Татарстан Республикасы спорт резервын әзерләүче Лениногорск муниципаль районының муниципаль физкультура спорт оешмаларын җиһазландыру өчен спорт җиһазлары, экипировка һәм инвентарь сатып алу | «Яшьләр эшләре спорт һәм туризм идарәсе» МКУ | 2026 | Республика бюджеты | 776,24 |
| 4. | | | Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Нефтяник" хоккей буенча» спорт мәктәбе» ӨББ МБУ спорт командаларының шайбалы хоккей буенча Татарстан Республикасы Чемпионатында һәм шайбалы хоккей буенча Россия Федерациясе Чемпионатында (А төркемчәсе)спорт әзерлеге программаларын гамәлгә ашыру һәм спорт командаларының катнашуы | «Яшьләр эшләре спорт һәм туризм идарәсе» МКУ | 2026 | Республика бюджеты | 894,10 |
| 5. | | | Лениногорск муниципаль районының спорт мәктәпләре спортчыларын ташу хезмәтләрен аутсорсинглау белән бәйле чараларны гамәлгә ашыру. | «Яшьләр эшләре спорт һәм туризм идарәсе» МКУ | 2026 | Республика бюджеты | 1397,36 |
| | | | | | 2026 | Җирле бюджет | 13,98 |